**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең Тышкы элемтәләр департаменты турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Тышкы элемтәләр департаменты турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаментын төзү турында» 1995 елның 1 августындагы ПУ-504 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 15 июлендәге ПУ-258 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-621 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 18 маендагы ПУ-420 номерлы Указының 7 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 9 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты указлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында» 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларының үз көчен югалткан нигезләмәләре исемлегенең 7 пункты.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2023 ел, 11 май
№ 290

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның « 11 » маендагы
290 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Рәисенең Тышкы элемтәләр департаменты турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Тышкы элемтәләр департаменты (алга таба – Департамент) халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыруда Татарстан Республикасы Рәисенә ярдәм итү максатында оештырылган Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора.

2. Департамент үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы шартнамәләренә һәм килешүләренә, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларына һәм шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Чит ил партнерлары белән эшне Департамент дипломатик багланышлар турында Вена конвенциясе нигезләмәләрен, халыкара практикада гомум кабул ителгән аралашу нормаларын, тышкы эшчәнлектә катнашучылар арасындагы мөнәсәбәтләр характерын, Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында барлыкка килгән беркетмә гамәлен исәпкә алып төзи.

4. Департамент турыдан-туры Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә буйсына.

5. Департамент турында нигезләмәне Татарстан Республикасы Рәисе раслый.

## II. Департаментның төп бурычлары

6. Департаментның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасының халыкара, тышкы икътисадый элемтәләрен һәм төбәкара багланышларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Рәисе эшчәнлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасының халыкара, тышкы икътисадый элемтәләрен һәм төбәкара багланышларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм алар буйсынуындагы оешмалар эшчәнлеген координацияләү;

Татарстан Республикасының чит илләрдәге, халыкара оешмалардагы, Россия Федерациясе субъектларындагы вәкиллекләре эшчәнлеген координацияләү;

Татарстан Республикасының халыкара, тышкы икътисадый элемтәләрен һәм төбәкара багланышларын, башка ил халыклары, чит илләрдә яшәүче ватандашлар белән хезмәттәшлекне үстерүгә булышлык күрсәтү.

## III. Департаментның төп функцияләре

7. Департаментның төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасының халыкара, тышкы икътисадый элемтәләре һәм төбәкара багланышлары мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе эшчәнлеген мәгълүмати-аналитик тәэмин итү, шулай ук күрсәтелгән мәсьәләләрдә Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча белешмә материаллар әзерләү;

Татарстан Республикасының Россия Федерациясе субъектлары, чит илләрнең федератив дәүләтләре субъектлары белән элемтәләрне үстерү, чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре, шулай ук чит ил дәүләтләренең дәүләт хакимияте органнары һәм халыкара оешмалары белән законнарда билгеләнгән тәртиптә ике яклы һәм күпъяклы мөнәсәбәтләрнең барлык комплексы буенча мәгълүматларны анализлау, төбәкара хезмәттәшлек, халыкара проблемалар мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләү һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә тапшыру;

Татарстан Республикасының Россия Федерациясе субъектлары, чит илләрнең федератив дәүләтләре субъектлары белән элемтәләрне, чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре, шулай ук чит дәүләтләрнең дәүләт хакимияте органнары һәм халыкара оешмалары белән законда билгеләнгән тәртиптә сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, мәдәни һәм башка төрле багланышларны киңәйтү буенча программалар һәм чаралар эшләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе уздыра торган чараларны координацияләү һәм Татарстан Республикасы Рәисе

Администрациясе хезмәткәрләренең халыкара багланышлары максатка ярашлылыгы мәсьәләсен килештерү;

Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куела торган шартнамәләр һәм килешүләр проектларын, халыкара, тышкы икътисадый элемтәләр һәм төбәкара багланышлар мәсьәләләренә карый торган тармакара килешүләр һәм беркетмәләр проектларын әзерләү һәм карау, алар буенча бәяләмә бирү, аларның үтәлешенә контрольлек итү;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген алып баручы оешмалар һәм дәүләт органнары, чит ил дәүләтләре территориясендә үз эшчәнлеген алып баручы оешмалар, Россия Федерациясе субъектлары, шулай ук халыкара оешмалар арасында үзара хезмәттәшлекне координацияләү;

халыкара, тышкы икътисадый элемтәләрне һәм төбәкара багланышларны гамәлгә ашыру мәсьәләләрендә билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы һәм башка федераль башкарма хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлек итү;

халыкара, тышкы икътисадый һәм төбәкара элемтәләрне тормышка ашыру мәсьәләләре буенча чит дәүләтләр органнары һәм халыкара оешмалар, чит дәүләтләрнең Россия Федерациясендәге дипломатик һәм консуллык вәкиллекләре белән үзара хезмәттәшлек;

төбәкара багланышларны тормышка ашыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлек;

Татарстан Республикасында дипломатик һәм консуллык өстенлекләре һәм иммунитетлар сакланышын тәэмин итүгә, Татарстан Республикасында чит ил дәүләтләренең вәкиллекләре һәм халыкара оешмалар эше өчен дипломатик практикада гомум кабул ителгән шартлар тудыруга ярдәм итү;

Татарстан Республикасы Рәисе кушуы буенча үз вәкаләтләре кысаларында массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасының халыкара, тышкы икътисадый элемтәләре һәм төбәкара багланышлары эшчәнлеге мәсьәләләре буенча аңлатма биреп чыгыш ясау;

күргәзмәләрдә, семинарларда, симпозиумнарда, конференцияләрдә катнашу һәм аларны оештыру аша дөнья җәмәгатьчелегенә Татарстан Республикасын таныту юнәлдерелгән эшчәнлекне тормышка ашыру;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе йөкләмәсе буенча Департамент башка функцияләрне башкара.

## IV. Департаментның хокуклары

8. Үз бурычларын һәм функцияләрен үтәү өчен Департамент түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратыннан,

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, Татарстан Республикасы дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материаллар соратырга һәм алырга;

билгеләнгән тәртиптә дәүләт элемтә системаларыннан һәм коммуникацияләреннән файдаланырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларында булган мәгълүматтан файдаланырга;

Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән килешеп, аерым эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) өчен галимнәрне, экспертларны, белгечләрне, тәрҗемәчеләрне, экскурсоводларны җәлеп итәргә;

Россия Федерациясе законнары нигезендә Департамент эшчәнлегенә кагылган мәсьәләләр буенча чит илләрнең хөкүмәт һәм хөкүмәтнеке булмаган оешмаларына, халыкара оешмаларга мөрәҗәгать итәргә.

## V. Департаментның хезмәттәшлек итү даирәсе

9. Департамент үзенең функцияләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Югары Суды, Татарстан Республикасы Арбитраж суды, Татарстан Республикасы прокуратурасы, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең барлык структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары, башка оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

## VI. Җаваплылык

10. Департамент хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар буенча үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була.

## VII. Департамент эшчәнлеген оештыру

11. Департаментның структурасы һәм штатлар саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

12. Департамент эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Рәисе указы нигезендә вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган Татарстан Республикасы Рәисенең Тышкы элемтәләр департаменты директоры (алга таба – Департамент директоры) җитәкчелек итә.

13. Департамент директоры:

үз компетенциясе чикләрендә документларга кул куя һәм виза сала;

Департамент хезмәткәрләре арасында вазыйфаи бурычларны бүлә, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә аларның вазыйфаи регламентларын раслауга тапшыра;

Департаментның структур бүлекчәләре функцияләрен билгели;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Департамент хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләү, вазыйфадан азат итү, шулай ук бүләкләү һәм командировкага җибәрү турында тәкъдимнәр бирә;

Департаментка йөкләнгән бурычларның үтәлүе өчен җаваплы була.

14. Департамент директоры вакытлыча булмаган чорда аның вазыйфаларын Департамент директоры урынбасары яисә Департаментның башка вәкаләтле вазыйфаи заты башкара.

15. Департамент хезмәткәрләре Департамент директоры тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

___________